ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# “Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында” Татарстан Республикасы Законының 8 һәм 32 статьяларына һәм Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 29 статьясына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2016 елның 28 июнендә
кабул ителде

**1 статья**

“Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында” 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (2005 елның 25 октябрендәге 106-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2003, № 1, № 9 (II өлеш); 2005, № 10 (II өлеш); 2006, № 12 (I өлеш); 2007, № 11; 2008, № 3, № 10 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2009, № 12 (I өлеш); 2010, № 1 – 2, № 10 (II өлеш); 2011, № 5, № 11 (I өлеш); 2012, № 7 (I өлеш); 2013, № 2 (I өлеш), № 3, № 11 (I өлеш); 2014, № 5, № 6 (II өлеш), № 7, № 12 (II өлеш); 2015, № 7 (I өлеш); 2016, № 4) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 8 статьяда:
а) 7 өлешне үз көчен югалткан дип танырга;
б) 8 өлештә “һәм дәүләт хезмәте вазыйфалары белгечлекләрен” сүзләрен төшереп калдырырга;

2) 32 статьяның 2 өлешендә:
а) 3 пунктның “г” пунктчасында “Татарстан Республикасы Президенты билгели торган исемлек буенча” сүзләрен төшереп калдырырга;
б) 4 пунктның “в” пунктчасында “Татарстан Республикасы Президенты билгели торган исемлек буенча” сүзләрен төшереп калдырырга.

**2 статья**

Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 29 статьясындагы 2 өлешенә (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2013, № 6

(II өлеш); 2014, № 5, № 6 (II өлеш), № 12 (II өлеш); 2015, № 7 (I өлеш); 2016, № 4) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) 3 пунктның “г” пунктчасында “Татарстан Республикасы Президенты билгели торган исемлек буенча” сүзләрен төшереп калдырырга;

б) 4 пунктның “в” пунктчасында “Татарстан Республикасы Президенты билгели торган исемлек буенча” сүзләрен төшереп калдырырга.

**3 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ • АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан,Кремль
2016 елның 6 июле
№ 51-ТРЗ